Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Большенуркеевского сельского
поселения Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль
районының Зур Нөркәй
авыл җирлеге
Башкарма комитеты

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2024 елның 24 декабре

№ 20

Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 02.11.2010 ел, № 880 республика Министрлар Кабинеты карарына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга;

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Башкарма комитетының «белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 25.06.2021 ел, №10 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча Интернет урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкченен
урынбасары

А.Н.Сабитов